| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 17 октябре № 6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 6 апрелендәге 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 маддәсе нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указының 8 пункты белән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 6 апрелендәге 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6, 7 пунктларны төшереп калдырырга;

8 пунктта «яллаучыга яисә яллаучы вәкиленә, Лениногорск муниципаль районы башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә» сүзләрен «авыл җирлеге башлыгына» сүзләренә алмаштырырга»;

9 пунктта «муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, яллаучы яисә яллаучы вәкиле» сүзләрен төшереп калдырырга»;

10, 11 пунктларда «муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе яки яллаучы» сүзләрен «авыл җирлеге башлыгы» сүзләренә алмаштырырга»;

2. Әлеге карарны җирлекнең түбәндәге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, , Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»муниципаль
берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина